СОВЕТ МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«27» 09 2024 ел.

№ 106

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 июне 49 нчы номерлы «Мөлкәткә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлегенә, «Татарстан Республикасы территориясендә салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып,физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибенең бердәм датасын билгеләү турында»гы 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, Кече Лызи авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 июнендәге 50 нче номерлы «Мөлкәткә салым турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Кодексның 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына карата (гомуми мәйданы 1000 кв.м.дан артып киткән административ-эшлекле һәм сәүдә үзәкләреннән (комплексларыннан) һәм эчендәге бүлмәләрдән тыш, әлеге Кодексның 378.2 статьясы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата, шулай ук һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектларына карата 2%;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 2.6 пунктча белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән, гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артып киткән административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар) һәм эчендәге бүлмәләргә карата 2025-2027 еллар чорына 1,2% ;»;

1.3. 2.6 пунктчасын 3 пункт, 3 пунктны 4 пункт, 4 пунктны 5 пункт, 5 пунктны 6 пункт, 6 пунктны 7 пункт дип санарга.

2. Әлеге карарның гамәли көче 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының Интернет

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге Советы рәисе А.С.Исмагилов